**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ПРОФЕССИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**

**«АКТАНЫШСКИЙ ТЕХНОЛОГИЧЕСКИЙ ТЕХНИКУМ»**

# ОГСЭ.06. **«Татарский язык в профессиональной деятельности”**

**ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ**

Для среднего профессионального образования **по специальности**
**09.02.07. Информационные системы и программирование**

Актаныш, 2022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**
**ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ҺӨНӘРИ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
**“АКТАНЫШ ТЕХНОЛОГИЯ ТЕХНИКУМЫ”**

# ОГСЭ.06. **“Һөнәри эшчәнлектә татар теле”**

**УКУ ДИСЦИПЛИНАСЫ ПРОГРАММАСЫ**

**09.02.07. Мәгълүмати системалар һәм программалаштыру белгечлеге** буенча урта һөнәри белем бирү өчен

Актаныш, 2022

# Уку дисциплинасы программасы

"09.02.07. Мәгълүмати системалар һәм программалаштыру белгечлеге буенча урта һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында", 2016 ел 9 декабрь 1547 номерда чыгарылган РФ фән һәм мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә,

урта һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә төзелде

Программа төзүче мәгариф учреждениесе: *Актаныш технология техникумы*

Төзүче: *Әхмәтҗанова Хәмдия Әхтәм кызы, Актаныш технология техникумының татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы"ның методик комиссия утырышында каралды

беркетмә №1, 231 август 2022 ел.

| **Килешенде** | **Раслыйм** |
|---|---|
| ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы" ның уку - укыту эшләре буенча директор урынбасары<br>_________ / Нуруллин Р. З./<br>« 31 » август 2022 ел | ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы" директоры<br>_________ /Шәмсунова Л. Я./<br>Приказ № ___« 31 » август 2022 ел |

# Эчтәлек

бит

1. **Уку дисциплинасы программасының паспорты** 5 - 9

2. **Уку дисциплинасының төзелеше һәм эчтәлеге** 10 - 18

3. **Уку дисциплинасын тормышка ашыру шартлары** 19 - 21

4. **Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм билге** 22 - 30

## 1. Уку дисциплинасы паспорты

### Һөнәри эшчәнлектә татар теле

Бу программа һөнәри эшчәнлектә татар теле фәненнән Актаныш Технология техникумында белем алучы татар телле укучылар өчен төзелде һәм түбәндәге документка нигезләнеп эшләнде:

- Башлангыч һөнәри белем бирү училищелары һәм лицейлары өчен татар теленнән программа.

Татар теленнән программа белем эчтәлеген заман таләпләренә туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү бурычларын хәл итү максатында Актаныш Технология техникумы өчен төзелде. Ул һәр укучының татар теле һәм әдәбиятыннан түләүсез яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, һәр укучыга тигез мөмкинлекләр тудыра.

Программа нигезендә татар теленнән белем күләме билгеләнә, укыту - методик комплектлар эшләнә.

Тугыз сыйныф белеме белән килгән укучы, татар теле буенча төпле һәм системалы белемгә ия булырга тиеш.

Яшь буынны физик яктан һәм акыл хезмәтенә, җәмгыять һәм дәүләт тормышының барлык өлкәләрендә, фән һәм мәдәнияттә актив эшчәнлеккә сәләтле итеп тәрбияләү бурычын хәл итүдә, техникумда татар баласына ана теле һәм әдәбиятын тирәнтен бирү, аларны татар халкының тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыру хәзерге шартларда тагын да актуальләшә.

Гомуми белем бирүнең максаты - укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камильләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. Тәрбияви максат студентларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә. Шушы максатлардан чыгып, программада укучылар өчен бурычлар куела:

- мәктәптә алган белемнәрне тирәнәйтү;

- укучыларны татар әдәби телендә иркен сөйләшергә өйрәтү, аларга ана телендәге әдәбиятны мөстәкыйль укып аңлау һәм үз фикерләрен сөйләмә яки язма рәвештә формалаштыра белү күнекмәләре бирү;

- татар әдәбияты һәм халык авыз иҗатының бай тарихына күзәтү ясау;

- татар телен һәм әдәбиятын укыту дәверендә һәм дәресләрдән тыш үткәрелгән чараларда студентларның рухи дөньяларын баету, патриотик, әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү, милли үзаң һәм милли горурлык хисләре тәрбияләү.

Тәкъдим ителгән программа " Башлангыч һөнәри белем бирү училищелары һәм лицейлары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан программа" га һәм дәреслекләргә нигезләнеп төзелде:

- Зәкиев М. З., Максимов Н. В. Татар теле. 10 -11 сыйныфлар өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2008;
- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;
- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017.

Һөнәри эшчәнлектә татар теле программасы (I курслар өчен) 72 сәгатькә исәпләнгән, нигездә, аларның аласы һөнәрләренә бәйләп, фонетика, лексика, морфология, синтаксис бүлекләрен өйрәнү каралып, изложение һәм сочинение күнекмәләре бирелә. Шулай ук телнең килеп чыгышы, тел галимнәре, диалектлар, татар телендә язу графикалары, телләр турындагы законнарны өйрәнү карала. Бүлек ахырында шулай ук изложение һәм сочинение язуга таләпләр күрсәтелә.

## 1.1. Программаны куллану тирәлеге

Уку дисциплинасы программасы урта башлангыч һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә эшләнгән төп белем бирү программасының бер өлеше булып тора. Бу программа **Мәгълүмати системалар һәм программалаштыру белгечлеге хәзерли торган группа студентлары** (022 ис) өчен төзелде.

Уку дисциплинасы программасы эшче һөнәрләре буенча өстәмә һөнәри белем бирү һәм һөнәри әзерлекләр өчен дә кулланыла ала.

**1.2. Төп һөнәри белем бирү программасы структурасында уку дисциплинасы урыны:** дисциплина гомумбелем бирү циклына керә.

## 1.3. Уку дисциплинасының максаты һәм бурычлары – дисциплинаны үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр.

***Татар теле фәнен үзләштергәннән соң студент белергә тиеш:***
Фонетик һәм орфоэпик принципларны, орфографик һәм грамматик кагыйдәләрне дөрес итеп урынлы куллана белергә; җөмләгә билгеләмә бирергә, әйтелешләре ягыннан җөмлә төрләрен, җөмләнең баш кисәкләрен, җөмләнең иярчен кисәкләрен, җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аера белергә. Ияртүле һәм тезүле бәйләнешне аера белергә . Татар теленең сүз байлыгын барлап, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә. Татар клавиатураларын, сөйләм үзенчәлекләрен, сөйләм техникасын, стильләрне, эш кәгазьләре төрләрен белергә.
***Эшләргә тиеш***: Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аерырга. Җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куярга. Чиста һәм орфография кагыйдәләрен дөрес кулланып язарга, үз фикерләрен сөйләм һәм язма формаларда логик яктан эзлекле, төгәл һәм җыйнак итеп биреп эшләргә тиеш.

Татар теленең сүз байлыгын барларга, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним, омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә. Сөйләм техникасын, стильләрне, эш кәгазьләрен яза белергә. Һөнәре буенча эшләгәндә татар телен иркен кулланырга.

**Тәрбия программасын тормышка ашыруның шәхси нәтиҗәләре:**

Ш.Н.1. Үзен яхшы белүче бөек ил гражданины һәм яклаучысы.

Ш.Н.2. Актив гражданлык позициясен, намуслылык, ачыклык принципларына тугрылык күрсәтүче, икътисадый актив; студентлар һәм территориаль үзидарәләрдә, иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә катнашучы, шул исәптән ireклелек шартларында нәтиҗәле хезмәттәшлек итүче.

Ш.Н. 3. Хокук тәртибе нормаларын үтәүче, гражданлык җәмгыяте идеалларының иминлеген, Россия гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүче. Субкультура вәкилләренең җайланмаларга һәм чагылышларына тугры, аларны деструктив һәм девиант тәртипле төркемнәрдән аеручы. Тирә-юньдәгеләрнең каршылыгын күрсәтеп, социаль куркыныч тәртибен кисәтүче.

Ш.Н. 4. Хезмәт кешеләренә хөрмәт күрсәтүче һәм үз хезмәтенең кыйммәтен белүче. Шәхси һәм профессиональ конструктив «цифрлы эз» челтәр мохитендә формалашырга омтылучы.

Ш.Н. 5. Туган мәдәнияткә, Ватанга, туган илгә, кече Ватанга мәхәббәт нигезендәге тарихи хәтергә тугрылык күрсәтүче, Россиянең күпмилләтле халкының традицион кыйммәтләрен кабул итүче.

Ш.Н. 6. Өлкән буын кешеләренә хөрмәт күрсәтүче һәм социаль ярдәмдә һәм волонтерлык хәрәкәтләрендә катнашырга әзер.

Ш.Н.7. Кеше шәхесенең өстенлекле кыйммәтен танып, төрле ситуацияләрдә, барлык эшчәнлек формаларында, төрләрендә үзенең һәм башкаларның уникальлеген хөрмәт итүче.

Ш.Н. 8. Күпмилләтле Россия Дәүләтенең мәдәни традицияләрен һәм кыйммәтләрен саклау, арттыру һәм трансляцияләү белән берлектә, төрле этномәдәни, социаль, конфессиональ һәм башка төркемнәр вәкилләренә хөрмәт күрсәтүче.

Ш.Н. 9. Сәламәт һәм куркынычсыз яшәү рәвеше алып бара: спорт кагыйдәләрен үти һәм пропагандалый; алкоголь, тәмәке, психоактив матдәләр, уеннар, наркомания һәм башкаларны кисәтә яки җиңә.

Ш.Н.10. Әйләнә-тирә мохитне: үзенең һәм башкаларның куркынычсызлыгын саклый.

Ш.Н.11. Эстетик культура нигезләренә ия булган эстетик кыйммәтләргә хөрмәт күрсәтүче.

Ш.Н.12. Гаилә кыйммәтләрен кабул итүче, гаилә коруга һәм балалар тәрбияләүгә әзер; гаиләдә көч куллануны кире кагучы һ. б.

**4. Уку дисциплинасы программасын үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләр саны:**

укучыга максималь уку йөкләнеше 72 сәгать, шуңардан

мәҗбүри уку дәресе 72 сәгать

мөстәкыйль дәресләр  0 сәгать

# Уку дисциплинасының төзелеше һәм якынча эчтәлеге

## 2.1. Уку дисциплинасының зурлыгы һәм уку эшләренең төрләре

| **Уку эшләренең төрләре** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| **Максималь уку йөкләнеше (барлыгы)** | **72** |
| **Мәҗбүри уку йөкләнеше (барлыгы)** | **72** |
| шуңардан: | |
| практик дәресләр | - |
| контроль – язма эшләр | 10 |
| **Укучының мөстәкыйль эшләре (барлыгы)** | - |
| шуңардан: | |
| мөстәкыйль эшләрнең тематикасы | - |
| сөйләм телен үстерү | - |
| тестлар | - |
| рефератлар | - |
| **Йомгаклау аттестациясе  -** дифзачёт | |

## 2.2. “Һөнәри эшчәнлектә татар теле” уку дисциплинасының эчтәлеге һәм календарь – тематик план

| **Бүлек һәм теманың исеме** | **Уку материалының эчтәлеге, практик дәресләр, студентларның мөстәкыйль эше** | **Сәгать саны** | **Үзләштерелү дәрәҗәсе** |
|---|---|---|---|
| **I бүлек. Һөнәри аралашу телендә татар теле** | | **6** | |
| Тема 1.1 Техникумда минем профессия. | Техникумда белем алу. Профессиональ белем алу системасы. Минем белгечлек. Карьера мөмкинлекләре. | 2 | 1 |
| Тема 1.2 Компьютер программалары. Заман таләпләре. | Татар телен өйрәнү программалары. Эшлекле өлкәдә – компьютер. Эш алып баруда икетеллелек турында ТР законы. | 2 | 1 |
| Тема 1.3 Компьютерны куллану. | Эшлекле татар теле өлкәсендә компьютер куллану. Татар клавиатурасы. | 2 | 2 |
| **II бүлек. Тел һәм сөйләм** | | **10** | |
| Тема 2.1. Тел һәм сөйләм. Тел һәм сөйләмнең төп берәмлекләре, функцияләре. | Тел һәм сөйләм. Тел һәм сөйләмнең төп берәмлекләре, функцияләре. Тел һәм сөйләм арасында аерма. | 2 | 1 ШН1 |
| Тема 2.2 Сөйләмгә мөнәсәбәтле ситуацияләр | Сөйләмгә мөнәсәбәтле ситуацияләр һәм аларның төрләре. Ситуацияләргә күзәтү ясау. Сөйләм ситуациясендә сөйләм элементлары: сөйләүче, тыңлаучы, сөйләмнең темасы, вакыты, урыны, максаты, сәбәбе. Аларга күзәтү. | 2 | 1 |
| Тема 2.3 Сөйләм төрләре. Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре. | Сөйләм төрләре. Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре. Телдән һәм язма сөйләм төзү күнегүләре. | 2 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 2.4 Сөйләм компетентлыгы | Сөйләм компетентлыгы турында төшенчә. Һөнәри сөйләм культурасы. Сөйләмнең иҗтимагый аспектлары. Сөйләм дөреслеге. Сөйләмнең эчтәлекле булуы. Сөйләм төгәллеге. Сөйләм аныклыгы. Сөйләм чисталыгы. Сөйләмнең сәнгатьлелеге, сыгылмалыгы Сөйләмнең байлыгы, матурлыгы һәм анда тел чараларын куллану. Сөйләмнең урынлы булуы. | 2 | 1 |
| Тема 2.5 Сөйләм техникасы | Сөйләм техникасы. Сулыш алу, тавыш, дикция, интонация. Сөйләмдә басым. Сәнгатьле сөйләм өчен партитура төзү. Сәнгатьле уку. | 2 | 2 |
| **III бүлек. бүлек. Сөйләмгә мөнәсәбәтле стиль ситуациясе** | | **24** | |
| Тема 3.1 Стилистика. Стиль. Стилистиканың роле. | Стилистика. Стиль. Стилистика фәне турында төшенчә. Стилистиканың әһәмияте. Әдәби тел нормалары. “Вертикаль” яктан стильләр. Сөйләм үзенчәлекләре. Сөйләмнең функциональ стильләре. Матур сөйләм сәнгатенә хас билгеләр,хәзерге сөйләм теле этикасы нормалары. Сүзнең асылы, | 2 | 2 ШН1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сөйләмдә аның төп роле.<br>Логик эзлекле, эмоциональ, ышандырырлык вербөтен мәгънәгә ия булган сөйләм телен үстерү. | | | |
| Тема 3.2 Әдәби сөйләм һәм язма стильләр. Фәнни стиль. | Әдәби сөйләм һәм язма стильләр, аларның төрләре. Фәнни, рәсми-канцелярия, иҗтимагый-публицистик, хатлар һәм матур әдәбият стиле. Стильләрнең кулланылыш сферасы. Фәнни стиль. Фәнни стильгә хас үзенчәлекләр. Фәнни стиль жанрлары. Публицистик стиль. Доклад, реферат, шәхси проект, чыгарылыш квалификацион эш, автореферат язуга таләпләр. Фәнни<br>– проект эшчәнлеге. | 2 | 2 | |
| Тема 3.3 Публицистик стиль. Татар матбугаты тарихы һәм бүгенге торышы. | Татар халкында матбугатның формалашуы. Татар матбугатының барлыкка килүе, үсеше өчен алшартлар. Аның халыкка, аң үсешенә йогынтысы. Җәмгыятьтә тоткан урыны. Матбугатны формалаштыручы, үстерүгә өлеш керткән шәхесләр. | 2 | 2 | ШН1 |
| | Публицистик стиль үрнәкләре белән танышу, аларга күзәтү ясау. | 2 | | |
| Тема 3.4 Фәнни стиль жанры: **рецензия.** | Рецензия. Рецензия язуга төп таләпләр. Газета һәм журналларны рецензияләү. | 2 | 2 | ШН12 |
| Тема 3.5 Фәнни стиль жанры: **аннотация.** | Аннотация – текстның, китапның кыскача эчтәлеген бирү, күзәтү ясау, анализлау, китапка үз фикереңне белдерү. Аннотация язарга өйрәнү, сакланырга тиеш<br>төп шартлар. Әдәби әсәрләргә аннотация язу. | 2 | 2 | |
| Тема 3.6 Рәсми-канцелярия стиле. Гариза, резюме, сыйфатнамә язу. | Рәсми-канцелярия стиле. Рәсми-канцелярия стиленә хас үзенчәлекләр. Рәсми-канцелярия стиле жанрлары.<br>Гариза – язма рәвештә рәсми формада язылган шәхси үтенеч. Гаризаның төрләре. Гаризаны дөрес, грамоталы итеп язарга өйрәнү.<br>Сыйфатнамә. Төркемдәшеңә сыйфатнамә язу. Резюме. Үз резюмеңны тутыру принципларын үзләштерү. | 2 | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Тема 3.7 Мәгълүматнамә, расписка, беркетмә. | **Мәгълүматнамә, расписка язуга таләпләр.** Шартнамәләр. Төрләре. Төзү тәртибе. Мәгълүматнамә – җитәкчегә эш турында язма рәвештә бирелә торган рәсми мәгүлүмат. Мәгълүматнамә язарга өйрәнү.<br>Беркетмә – җыелыш, киңәшмә, утырышларның барышын төгәл язып баручы документ. Беркетмә язарга өйрәнү. | 2 | 2 | ШН1 |
| Тема 3.8 Акт, ышанычнамә язуга таләпләр. | **Акт, ышанычнамә язуга таләпләр.** Ышанычнамә. Билгеләмә. РФ ГК ның 185- 189 статьялары. Төрләре. Ышанычнамә тутыруга төп таләпләр. Акт – нинди дә булса юридик факт турында документ. Актны грамоталы төзергә өйрәнү. | 2 | 2 | |
| | Хатлар стиле. Хатларның төрләре. Хатларның төрләренә карап, аларны язу стиле. Хатлар. Төрләре. Рәсми һәм шәхси<br>хатлар. Күмәк, матбугат, ачык хатлар. Җавап таләп итүче һәм җавап таләп итмәүче хатлар. | 2 | 2 | ШН12 |
| Тема 3.9 Иҗтимагый-публицистик стиль. | Иҗтимагый-публицистик стиль. Иҗтимагый- публицистик стиль үзенчәлекләре. Төп жанрлары. | 2 | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Мәкаләязу. | | |
| Тема 3.10 Матур әдәбият стиле. | Матур әдәбият стиле. Матур әдәбият стилендәге текстларның төрләре, жанрлары. Әдәби әсәрләрнең композициясе. Әдәби әсәрләрнең теле. Матур әдәбият стиле, стилистик бизәкләр. Төшенчәләрне белдерүдә синонимнарның роле. Образлы сөйләмдә капма – каршылыклы белдерүнең махсус чарасы буларак – антоним. Төшенчә һәм образ. Сүзнең эчке формасы һәм образлылык.<br>Бүлек буенча белемнәрне системалаштыру, тикшерү. | 2 | 2 ШН12 |
| **IVбүлек. Һөнәри юнәлешле текстлар. Текст төзелеше** | | **8** | |
| Тема 4.1 Һөнәри сөйләмне үзләштерү объекты буларак текст. | Сөйләмнең төп өйрәнү объекты буларак текст. Текст һәм аның микро һәм макротекстка бүленүе. Текст һәм абзац. Текстның мәгънәви, коммуникатив, структур, грамматик бөтенлеге. Текст композициясе. | 2 | 1 |
| Тема 4.2 БСҮ Һөнәри юнәлешле текст буенча тыгыз (сжатое) изложение. | Бирелгән һөнәри юнәлешле текст буенча тыгыз (сжатое) изложение язу. | 2 | 3 |
| Тема 4.3 Һөнәри сөйләмгә мөнәсәбәтле тел ситуациясе. Һөнәри темага әңгәмә. | Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. Әзерлексез чыгыш ясауның үзенчәлекләре: үз-үзеңне тота белү (мимика), сөйләмнең төп фикерен җиткерә белү, кереш һәм йомгаклау сүзен формалаштыру. | 2 | 2 ШН1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Тема 4.4 Һөнәри темага әңгәмә, фикер алышу | Әңгәмә коруның төп юнәлешләре. Әңгәмә - иҗтимагый тормышның иң әһәмиятле бер күренеше:<br>- Әңгәмәнең асылы һәм аның типлары: якыннарың белән әңгәмә; таныш булмаган кеше белән әңгәмә; эшлекле әңгәмә; өстәл яны әңгәмәсе.<br>- Әңгәмә коруның ике моделе: “ачык” сөйләм һәм “ябык” сөйләм.<br>Комплимент һәм тостлар әйтә белү. Әңгәмә коруның төп юнәлешләре. | 2 | 2 | |
| **V бүлек. Һөнәри лексика һәм сөйләм культурасы** | | **22** | | |
| Тема 5.1 Татар теленең лексикасы.<br>Лексикология.<br>Лексикография.<br>Сүзлекләр. Төрләре. | Лексика, лексикология төшенчәләре. Семасиология, этимология, фразеология, лексикография, ономастика. Сүзлекләр. Төрләре. Функцияләре. Сүзлекләргә күзәтү, характеристика бирү.<br>Көнкүреш сөйләм теленең кулланылыш сферасы,<br>лексика составы. Дублет һәм күрсәткеч сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы һәм урыны. | 2 | 2 | ШН1 |
| Тема 5.2 Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Сүзнең күпмәгънәлелеге | Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Күчерелмә мәгънәле сүзләрнең стилистик кулланылышы. Сүз мәгънәләре. Сүзнең күпмәгънәлелеге. Күпмәгънәле сүзләр һәм сөйләм культурасы. Омонимнар. Омонимнарның төрләре. Омонимнарның стилистик к Синонимнар. | 2 | 2 | ШН12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 5.3 Фразеологик берәмлекләр. Аларны сөйләмдә куллану. | Фразеологик берәмлекләр. Аларны сөйләмдә куллану. Фразеология һәм сөйләм культурасы. Фразеологик берәмлекләрнең төп билгеләре һәм аларның төрләре. Фразеологизмнарның стилистикасы. | 2 | 2 |
| Тема 5.4 Килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы. | Татар теленең сүзлек составы һәм сөйләм культурасы. Килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы. Татар теленең нигезе буларак гомумтөрки сүзләр. Татар телендә алынмалар. Татар телендә гарәп- фарсы, рус, европа телләреннән алынган сүзләр. Аларның сөйләмдә кулланылышы. | 2 | 2 |
| Тема 5.5 Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. | Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Татар теленең сүзлек составында актив һәм пассив катламнар. Искергән сүзләр буларак тарихи сүзләр һәм архаизмнар. Яңа сүзләр (неологизмнар) һәм аларның барлыкка килү юллары. Татар теленең<br>диалекты. | 2 | 2 |
| | Татар теленең диалекты.<br>Диалект төрләре. Сөйләшләр. Урта диалект, Минзәлә сөйләше.<br>Диалекталь сүзләр туплау. | 2 | |
| Тема 5.6 Сөйләмнең сәнгатьчә сурәтләү алымнары | Сөйләмнең сәнгатьчә сурәтләү алымнары: эпитет, чагыштыру, метафоралар, метонимия, сынландыру, арттыру, антитеза, оксюморон, литота һ.б. Антитеза(төшенчәләрне капма –каршы куеп, фикер,фраза тудыру) һәм градация<br>(төшенчәләрнең мәгънәләре үсә һәм кими бару тәртибендә урнашуы) үзенчәлекләре.<br>Оксюморон (образны капма–каршылыклы күренешләрнең бердәмлеге аша сурәтләү) – үткен мәгънәле фикерне оештыручы фигура.<br>Сөйләмдә лексик хаталарның типлары | 2 | 2 ШН12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 5.7 Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. | Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. Әзерлексез чыгыш ясауның үзенчәлекләре: үз-үзеңне тота белү(мимика), сөйләмнең төп фикерен җиткерә белү, кереш һәм йомгаклау сүзен формалаштыру.<br>Риторик эндәш һәм сорау – сөйләмдә әһәмиятле мәгънәви позицияне билгеләү, тыңлаучының фикерен үзең теләгәнчә формалаштыру өчен кулланыла торган фигуралар. | 2 | 2 ШН1 |
| Тема 5.8 Терминологик сүзлекләр белән эш | Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш. Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау.<br>Сөйләм культурасы. | 2 | 2 |
| Тема 5.9 Һөнәри юнәлтелгән текстка лингвистик анализ. | Һөнәри лексика. Терминнар. Һөнәри юнәлешкә караган текстлар белән эш. Һөнәри лексика темасына сүзлек диктанты язу. Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш.<br>Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау. | 2 | 2 ШН12 |
| Тема 5.10 Һөнәри лексика өстендә эшләү. | Һөнәри лексика. Терминнар. Һөнәри юнәлешкә караган текстлар белән эш. Һөнәри лексика темасына сүзлек | 2 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | диктанты язу. Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш. Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау. Бүлекне йомгаклау. Белемнәрне ткшерү. | | |
| Һөнәри эшчәнлектә татар теле курсын йомгаклау. **Дифзачет.** | **Дифзачет.** | **2** | 3 |

72 сәгать

Уку материалын үзләштерү дәрәҗәсен характеристикалау өчен түбәндәге билгеләр кулланыла:

1- танышу (элек өйрәнелгән объектларны, үзлекләрне белү);

2- репродуктив (эшчәнлекне үрнәк, инструкция буенча яки җитәкчелек астында башкару);

3– продуктив (эшчәнлекне планлаштыру һәм мөстәкыйль башкару, проблемалы бурычларны хәл итү)

# 3. Уку дисциплинасын тормышка ашыру шартлары

## 3.1. Минималь материаль – техник тәэмин итүгә таләпләр

Уку дисциплинасын тормышка ашыру татар теле һәм әдәбияты кабинетын яхшыртуны таләп итә

Уку кабинетын җиһазлау:

Китапханә фонды (китап бастыру продукциясе)

- Татар теле һәм әдәбиятыннан төп гомуми белем бирү стандарты
- Татар теле һәм әдәбиятыннан урта (тулы) гомуми белем бирү стандарты
- Татар теле һәм әдәбиятыннан төп гомуми белем бирү өчен үрнәк программа
- Татар теле дәреслеге - 10 – 11сыйныфлар өчен
- Татар теле - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек
- Татар теле - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек
- Әдәбият дәреслеге 10 сыйныфлар өчен
- Әдәбият дәреслеге 11 сыйныфлар өчен
- Әдәбият - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек
- Диктантлар җыентыгы – 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Изложениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Сочинениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Татар теле һәм әдәбияты буенча бердәм дәүләт имтиханнары материаллары – җыентык
- Тестлар - җыентык
- Фәнни, фәнни – популяр, тарихи әдәбият
- Сүзлекләр, журналлар, альбомнар...

- Укытучы өчен методик китаплар

- Әдәби әсәрләр

## Басма ярдәмлекләр

- Татар теленнән таблицалар
- Әдәбияттан таблицалар
- Язучыларның портретлары

## Информацион – коммуникатив әсбаплар

- Әсәрләргә һәм язучыларга багышланган дисклар
- Әсәрләргә һәм язучыларга багышланган видеофильмнар

## Уку өчен техник чаралар

- Компьютер
- Проектор
- Экран

## - Уку - практик һәм уку – лаборатория җиһазлары

- Компьютер өстәле
- Җиһазларны саклау өчен бүлкәле шкаф
- Китап шкафы
- Укучылар санынча өстәлләр һәм урындыклар
- Укытучының эш урыны

**3.2. Укучыларны информацион тәэмин итү**

**Тәкъдим ителгән уку басмалары, интернет – ресурслар, өстәмә әдәбият**

Төп китаплар:

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф. Җамалиева. Татар әдәбияты. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- - Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф. Җамалиева. Татар әдәбияты. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017.

**Өстәмә китаплар:**

Дәрес эшкәртмәсе үрнәкләре. Казан – 2012. Татар теле һәм әдәбияты. Р. А. Зарипов, А. М. Юсипова, Г. Ә. Гайнетдинова, Г. Г. Әхмәдуллина.

Татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. Ә. Б. Шакирҗанова.

Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. Татар теле. Р. Р. Шәмсетдинова.

Олимпиадага әзерләү өчен ярдәмлек. Татар теле. Казан – 2014.

Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. "Гыйлем" нәшрияты. – 2015.

**Интернет – ресурслар:**

http://tatar.com.ru/ все для изучения татарского языка

http://kitap.net.ru/ татарская электронная библиотека

http:/www. Kitaphane.tatar.ru Национальная библиотека Республики Татарстан

http://tatar.info/ проект свободной многоязычной энциклопедии о татарской нации, её культуре, языке, истории и традициям

znanium.com

## 4. Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм билге

Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм билге контроль һәм мөстәкыйль эшләр, тестлар үткәргән һәм шулай ук укучылар индивидуаль биремнәр, зачётлар эшләгән вакытта укытучы тарафыннан тормышка ашырыла.

## II КУРС УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕЛЕМНӘРЕН БӘЯЛӘҮ

### ЯЗМА ЭШЛӘР

Тел буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатыннан татар теле дәресләрендә төрле язма эшләр — диктант, изложение һәм сочинениеләр яздырыла. Диктантларны бәяләгәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталарның саны, ә изложение белән сочинениеләрдә исә, орфографик һәм пунктуацион хаталар белән бергә, теманың ачылу дәрәҗәсе, язманың тел байлыгы (С), грамматик ялгышлары (Г.\, логик (Л.) һәм фактик (Ф.) хаталар да исәпкә алына.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>— фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>— татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>— җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр — иҗекләргә; җөмлә — сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>— тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса;<br>— интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «5»ле билгесе куела. |
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә ягъни:<br>— кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>— сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>— җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «4» ле билгесе куела. |
| 1.<br><br>2.<br><br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | «3»ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br><br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда; | «2» ле билгесе куела. |

Язма эшләрдә җибәрелгән хаталар тупас һәм тупас булмаган хаталарга бүленеп йөртелә.

Тупас хаталарга алдагы сыйныфларда һәм бу уку елында үтелгән орфографик, грамматик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган хаталар керә.

Тупас булмаган орфографик хаталар:

— укучы үзе төзәткән орфографик хаталар (өч хатасын үзе төзәткән укучының эше бер баллга түбән бәяләнә); язылышы татар теле кагыйдәләренә туры килмәгән ялгышлар (Акъегет, көньяк, төньяк, Сибгат һ. б.); мәгънәләре төрлечә кулланылган кушма яки тезмә сүзләрне бутап язу (аш казаны — ашказаны, бер үк — берүк, кай вакыт — кайвакыт, ике йөзле — икейөзле, ил гизәр — Илгизәр, өй алды — өйалды һ. б.);

— программа нигезендә өйрәнү күздә тотылмаган яки соңрак үтеләчәк теоретик материалларга караган орфографик хаталар;

— беренче тапкыр очраган алынма сүзләрне, шулай ук тар профессиягә караган атамаларны язудагы хаталар;

— дәреслектә күрсәтелмәгән очракларга караган сүзне юлдан юлга күчерүдә ялгышу.

Тупас булмаган пунктуацион хаталарга җөмлә эчендәге синтагмаларны яки кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен, функцияләре бердәй булган тыныш билгеләренең берсе урынына икенчесен кую (теркәгечләрдән башка бәйләнгән ике тиңдәш кисәкнең берсе икенчесенә каршы куюны белдергән очракта сызык яки өтер кую; гомумиләштерүче сүзләр янында — ике нокта яки сызык; аныклагычлар янына — сызык, ике нокта, җәяләр яки ике яктан өтер; ымлык яки аваз ияр-темнәреннән соң — өтер яки өндәү билгесе; теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә — өтер, нокталы өтер яки сызык; тиңдәш кисәкләр арасында — өтер яки нокталы өтер; иярченле кушма җөмләдә — өтер яки ике нокта; туры сөйләм янында — сызык, өтер яки сызык, күп нокта һәм сызык, ике нокта һәм сызык; тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую; берничә тыныш билгесе бергә очрашкан урыннарда ялгышу; үзара бик тыгыз бәйләнештәге гади җөмлаләрне өтер, сызык яки ике нокта белән аерып язу; тезмә кушма җөмләләрнең өлешләрен нокта белән аерып, шул фикерне гади җөмләләр итеп бирү) керә.

Контроль диктантларны бәяләү.

Бәяләү нормалары контроль диктант күләменнән чыгып бирелә. Язма эшләрнең күләме кимрәк яки артыграк булганда, нормалар да шуңа мөнәсәбәттә кими яки арта.

Сыйныфлар буенча контроль диктант күләме түбәндәгечә билгеләнә:

| Группалар | Сүзләр саны | |
|---|---|---|
| | уку елы башында | уку елы ахырында |
| I курслар | 150 | 160 |
| II курслар | 160 | 170 |

**Югарыда саналганнардан чыгып, контроль диктантлар түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаган эшкә.<br>**Искәрмә.** Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм пунктуацион бер хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела. «5» ле билгесе куела ала. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>**Искәрмә.** 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4» ле билгесе куела. «4» ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә **Искәрмә.** 4 пунктуацион. 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3» ле билгесе куела. «3»ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |

**Изложениеләрне бәяләү**

Изложение язу өчен, гадәттә, укучыга аңлаешлы телдә язылган хикәяләү характерындагы текст яки өзек алына. Ул матур яки фәнни-популяр әдәбияттан, көндәлек матбугаттан һ. б. алынырга мөмкин.

Нинди генә өзек яисә текст бирелсә дә, укучы аның язылу стиленә игътибар итәргә, стильләрне бутамаска тиеш. Текстның стиль үзенчәлекләре укучының язмасында да сакланырга тиеш.

Изложениенең күләме һәм эчтәлеге, сыйныфның әзерлегенә карап, укытучы тарафыннан сайлап алына.

Изложение өчен матур әдәбият һәм фольклор әсәрләреннән, вакытлы матбугаттан хикәяләү характерындагы өзекләр яки текст алына. Тезмә әсәрләр нигезендә изложение сирәк яздырыла.

Сайланган текстлар укучыларга белем һәм тәрбия бирү максатларын канәгатьләндерерлек, эчтәлеге һәм теле ягыннан аңлаешлы булырга, бәйләнешле сөйләм үстерү юнәлешендә алып барылырга тиеш.

Текст белән эшләү барышында укучыларның бәйләнешле фикер йөртә белү сәләте генә түгел, ана теленең орфографик, грамматик, стилистик һәм пунктуацион үзенчәлекләрен белүләренә, текст эчтәлегеннән чыгып, нәтиҗә ясый белү сәләтенә, сүз байлыгыннан файдалана белү мөмкинлекләренә дә бәя бирелә.

**Изложение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Текстның бирелеше | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Текст, планга нигезләнеп (яки плансыз), эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган; фактик һәм техник хаталар юк. | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар. | «5» ле билгесе |
| 2. | Тексттагы хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик, 1 техник хата җибәрелгән. | 2 орфографик, 1 пунктуацион (яки 1 грамматик) хата бар. | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган. Сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик, 2 техник хата җибәрелгән. | 3 орфографик, 2 пунктуацион,1 грамматик хата бар. | «3» ле билгесе куела. |
| 4. | Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган; стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар күп. | орфографик хаталарның саны өчтән, пунктуацион хаталарның саны икедән, грамматик хаталарның саны өчтән артык | «2» ле билгесе куела. |

**Сочинение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Эшнен эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; план буенча (яки плансыз) эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган. | 1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар | «5» ле билгесе куела. |
| 2. | Язманың эчтәлеге темага нигездә туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелегендә артык әһәмияте булмаган бозу сизелә; тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль, бердәмлеге сакланган. | 2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар. | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар. | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | 7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар. | «2» ле билгесе куела. |

Язма эштән соң беренче юлга, кызыл юл турысыннан башлап, ялгышларның саны күрсәтелә: башта орфографик, аннан соң пунктуацион һәм стилистик хаталар саны языла. Аларны ике нокта аша күрсәтергә була: 1:3:2. Бу язылыш 1 орфографик, 3 пунктуацион, 2 стиль хатасы барлыкны аңлата.